СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «12» апреленнән № 44-338

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниипаль районы Советының «Яңа редакциядә «Җирле үзидарә органында хезмәткәрнең персональ белешмәләре белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 11 ноябрендәге 37-218 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниипаль районы Советының 2014 елның 11 ноябрендәге 37-218 номерлы карары белән расланган район Советының 2021 елның 9 декабрендәге 16-129 номерлы карары редакциясендә) яңа редакциядә җирле үзидарә органында хезмәткәрнең персональ белешмәләре белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктча өстәргә:
«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗномерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма

рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов